# ТЕЛЕВИДЕНИЕ

**ШИМБӘ**
**30 НОЯБРЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.10 Сарман балалар бакчасында.
17.25 Очрашулар. А.Хәйруллина.
18.05 «Уятмакчы булсаң халык күңелләрен». Телевизион конкурс.
18.15 Яшь башкаручылар концерты.
19.00 Татарстан.
19.30 Әлли-бәлли-бәү.
19.40 ТССР Югары Советы сессиясендә.

**I ПРОГРАММА**

6.30 Ритмлы гимнастика.
7.00 Мультфильмнар.
7.30 Эшлекле кешенең шимбә иртәсе.
8.30 ТЯХ.
8.45 «Хезмәттәшлек» видеоканалы.
10.00 Безнең бакча.
10.30 Иртәнге күңел ачу программасы.
11.00 Режиссер С. Колосов фильмнары. «Анна Фирлингның юллары».
13.15 Карьера. Менеджерлар конкурсы. 3 нче тур.
14.30 Музыкаль киоск.
15.00 ТЯХ.
15.15 «Пи» билгесе астында.
16.10 Тхэквандо һәм хатын-кызлар.
16.20 Мультфильм: «Могҗизалы урман».
17.50 «Гаҗәеп шәһре Москов». 6 нчы фильм.
18.25 Фигуралы шуу.
19.25 Мультфильм: «Бал корты Майя».
19.50 Нәфис фильм премьерасы: «Каты адәм».
21.00 Информацион программа.
21.35 Зәңгәр конверт.
22.35 Теннис.
23.35 Телевизион яңалыклар хезмәте.
23.50 Европа плюс...
00.50 Нәфис фильм: «Барыгызга да рәхмәт...»

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 «Ревью-Кавказ».
9.00 Мультфильм.
10.00 Документаль фильм.
10.50 «Орнамент» ансамбле концерты.
11.00 «Плюс унбер» видеоканалы.
13.00 «Мәскәү—Бостон» телекүпере.
14.15 «Капитал».
14.45 «Виктор Ворошильский».
15.05 «Коткар һәм сакла».
15.55 «Сүз сорыйм».
16.10 «Төш юрау».
20.20 «Тыныч йокы, нәниләр».
20.35 «Санкт-Петербург балеты». 2 нче кисәк.
21.35 Коррупция.
22.05 «Тверскаядагы юбилей».
22.55 Реклама.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 «Иртәгәгә астрологик күрәзә».
23.25 Эстрада программасы.

**ЯКШӘМБЕ**
**1 ДЕКАБРЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.05 Нәфис фильм: «Вәсвәсә».
18.55 «Киң Иделдә» киножурналы.
19.15 Театр сәхифәләре. Ш. Сарымсаков. 2 нче тапшыру.
19.45 Әлли-бәлли-бәү.
20.05 В. Ганиева җырлый.

**I ПРОГРАММА**

8.00 Спорт һәркем өчен.
8.30 ТЯХ.
8.45 «Спортлото» тиражы.
9.00 Мәхәббәт аңлату.
9.15 Иртән-иртүк.
10.00 Ватанга хезмәттә.
10.40 Иртәнге йолдыз.
11.45 Сәяхәтчеләр клубы.
12.45 Экологик хроника
13.00 Авыл сәгате.
14.00 Җир—безнең уртак йортыбыз.
14.05 Сәламәтлек.
15.00 ТЯХ.
15.15 Туры эфирда әңгәмәләр.
16.00 Марафон-15.
17.00 Халыкара панорама.
17.45 Тавышлар күп—дөнья бер генә.
17.50 Уолт Дисней күрсәтә...
18.40 Нәфис фильм: «Сьерра Мадре хәзинәсе».
21.00 Информацион программа.
21.35 Футбол күзәтү.
22.05 Аншлаг, аншлаг.
23.25 ТЯХ.
23.40 Музыка СПИДка каршы.
01.10 Теннис. Дэвис кубогы.
01.50 «Безнең паровоз алга оча...»

**II ПРОГРАММА**

8.00 «Күнегүгә бас!».
8.15 Балалар программасы.
9.15 «Концерт риваятьләре».
10.15 Г. К. Жуковның туууына 95 ел тулуга багышланган тапшыру.
11.15 «Мин һәм башкалар».
12.30 «Ставрополье җире җиңелме?»
13.00 Ж. Сименон. «Куен дәфтәрендәге җиде тәре».
14.40 «Изге һәм мәңгелек».
14.55 «Тарих фонындагы этюд».
15. 25 «М. Цветаева».
22.20 «К-2» тәкъдим итә...
22.55 Реклама.
23.00 «Хәбәрләр».
23.20 «Иртәгәгә астрологик күрәзә».
23.25 «Республика казанышы». З. Шарко.


## «НОРЛАТ СӘҮДӘ ЙОРТЫ» ФИРМАСЫ

СЕЗГӘ ТЕЛӘСӘ НИНДИ ИСЕМДӘГЕ ТОВАРНЫ САТАРГА ҺӘМ САТЫП АЛЫРГА ТӘКЪДИМ ИТӘ.

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ ҺӘМ БЕЗГӘ КИЛЕГЕЗ, ЧЫННАН ДА БЕЗ СЕЗГӘ НИНДИ ТОВАР КИРӘКСӘ ШУНЫ САТЫП АЛА ҺӘМ СЕЗНЕҢ ТЕЛӘСӘ НИНДИ ӘЙБЕРЕГЕЗНЕ САТА АЛУЫБЫЗГА ИНАНЫРСЫЗ.

*Безнең адрес: Совет урамы, 117*
*Телефоннар: 2-14-69, 2-15-96.*


**ЯҢАЛЫКЛАР**

## ТЫЛСЫМЛЫ СУ

Пешү—коточкыч авыр нәрсә. Ел саен илебездә миллионлаган кеше бу җәфадан интегә. Статистика нәтиҗәләренә караганда, пешү очраклары күбәйгәннән-күбәя бара. Казан химия-технология институтында анолит һәм католит дигән яңа препаратлар уйлап тапканнар. Аларны пешүне дәвалау өчен бик нәтиҗәле файдалана башлаганнар. Анолит һәм католитның гаҗәеп мөмкинлекләре турында СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты, профессор П. Кирпичников сөйли:

—Анолитның ялкынсынуны тиз арада туктатуы, ә католитның төзәлү процессын тизләтүе билгеле булды. Әкияттәге кебек: башта «үле» суны, аннары «тере» суны бөркеп җибәрүең була, җәрәхәт төзәлә дә башлый. Гадәттәге антисептиклар белән дәвалауга караганда, болар белән дәваланудан кеше берничә көн алданрак сәламәтләнә. Алар белән бронхит һәм озакка сузылган пневмонияне дәвалау да уңай нәтиҗәләр бирә.

—«Тылсымлы су» кешегә генә хезмәт итәчәкме?

—Юк. Бу препаратлар, мәсәлән, терлек абзарларын йогышсызландыру өчен дә кулланыла. Шуның өстенә алар ярдәмендә мал-туарны, кошкортны исән-имин саклап калу һәм аларның продукт бирүчәнлеген арттыру өлкәсендә дә тикшерүләр алып барыла. Бозаулар, дуңгыз балалары, безнең препаратларны кушып ясаган сыекчаны эчкәннән соң, тизрәк үсәләр. Безнең бу суыбыз силос, бәрәңге, яшелчә консервлаганда, йомырканы сальмонеллездан арындыру өчен дә кулланыла.

**Т. ПЕТРОВА.**
(«Шәһри Казан» газетасыннан).

## Пенсия алырга—күрше авылга

Хәзерге кыен чорда сугыш һәм хезмәт ветераннарына аеруча авырга туры килә. Алар сәгатьләр буенча продуктка һәм башка кирәк-ярак товарларга чират торалар. Болары көндәлек мәшәкатьләр. Ә менә гомере буена эшләп алган пенсия артыннан икенче авылга йөрүе үзе аяныч.

Кемнәр инде алар димәгез. Алар Ерепкино авылы пенсионерлары. Элек, Данил Ухванов хат ташучы булып эшләгәндә, картлар, карчыклар пенсия акчасын кул куеп өйләрендә генә алалар иде. Хат ташучы вафат булгач, 1990 елдан башлап Ерепкино картлары авыр хәлдә калдылар: пенсия алу өчен күрше Аксумла авылына җәяүләп йөриләр. Ә бит бер барып кына акчасын да алып булмый, берничә кат барырга да туры килә. Ерепкино авылы аша узучы автобус картларны бик сирәк кенә утыртып китә.

Көзге пычракларда, кышкы буранлы салкын көннәрдә карт кешеләргә, бигрәк тә чирлеләргә ике авыл арасын (5 километр юлны) үтүе җиңел түгел, билгеле.

Ерепкино авылы пенсионерлары кайчанга кадәр шулай иза чигәрләр, аларның үтенеченә район элемтә узелы җитәкчеләре нинди җавап бирерләр икән?

**И. ЕРЕПОВ.**



Күңелле тамаша. С. Майстер фотосы.

## Ярдәм көтәбез

29 сентябрьдә Чулпан авылында безнең хуҗалыкта янгын чыкты. Андый хәлләр булгалап торганга, бәлки бу очрак турында аерым тукталып торуның кирәге дә юктыр. Тик безнең әйтәсе килгәнебез —авылның ут сүндерүгә көйләнгән машинасы булмавы. Дөресрәге, машинасы бар, ләкин аның насосы эшләми.

Алда китерелгән очракта да машина вакытында килеп җитүдә ни файда, төзек булмагач, ул безгә берни ярдәм итә алмады.

Ә иң аянычы—ул бүгенге көнгә кадәр көйләнмәгән хәлдә. Сентябрьдә фаҗига безнең гаиләгә килсә, иртәгә ул башкаларга килмәс дип кем әйтә ала?! Ут сүндерү өчен махсус билгеләнгән машинаны башка хуҗалык эшләрендә кулланып ватып аттылар, көйләп, әзерләп кую турында уйлаучы да юк. Димәк, киләчәктә дә башына төшкән кеше бәла белән бер ялгызы калачак. Ә ягадан, Норлаттан ярдәм килгәнче, саклар әйбер дә калмаячак, янып бетәчәк.

Без, Чулпан авылы кешеләре, мондый битарафлыкны җинаять дип саныйбыз һәм хуҗалык җитәкчеләренең бу мәсьәләгә йөз белән борылуларын телибез. Ә газетабыз моңа ярдәм итәр дип ышанабыз.

**Г. МОСТАФИН.**
Чулпан авылы.

## Иң зур эш стажы

Иң зур эш стажы—98 ел—Тын океандагы Токуношимо утравында урнашкан Асаннан Изуми Шигечийо хисабында. Ул 1865 елда туган, Япониядәге беренче халык исәбен алу вакытында теркәлгән була. Үзенең хезмәт эшчәнлеген 1872 елда шикәр ваклагычта хайваннарны куучы булып башлый. Эшләвен 1970 елда 105 яшендә шикәр камышы үстерүче фермер сыйфатында туктата. 1986 елда 120 яше тулганда үпкә ялкынсынуыннан үлә.

## РӘХМӘТЕБЕЗНЕ БЕЛДЕРӘБЕЗ

Кадерле әтиебез К. А. Хәсәновның үлүе сәбәпле безнең тирән кайгыбызны урлаклашулары, авыр вакытта мораль һәм материаль ярдәм итүләре өчен «Норлатнефть» НГДУсы җитәкчеләренә һәм барлык коллективка олы рәхмәтебезне белдерәбез.

**ХАТЫНЫ, БАЛАЛАРЫ.**

### ТАБЫЛДЫКЛАР ӨСТӘЛЕНӘ

Норлат шәһәре урамнарының берсендә сумка табылды. Акчасы да бар. Югалтучы Гагарин урамы 1 нче йорт 20 фатирда яшәүче Ухвановларга (кичке 18 сәгатьтән соң) мөрәҗәгать итсен.


**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.
Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

ТССР информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе.

Күләме—1 басма табак.

Заказ 143. Тираж 3413.